| | | |
|---|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>СОВЕТ МАМАШИРСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>КУКМОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КУКМАРА<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>МӘМӘШИР АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ** |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

Мәмәшир авылы

«31» октябрь, 2023 ел № 29

Җир салымы турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге нигезендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРДЕ:

1. Түбәндәге салым ставкалары күләмен билгеләргә:

1.1. 0,3 % – авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләргә караган яисә торак пунктларда авыл хуҗалыгы өчен кулланыла торган һәм авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен кулланыла торган җирләр составына кертелгән җир кишәрлекләренә карата;

1.2. 0,1 % – торак фонды һәм (яки) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары биләгән (торак фондына һәм (яки) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына карамаган күчемсез милек объектына туры килгән җир кишәрлеге өлешеннән тыш) яисә торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) (эшмәкәрлек эшчәнлегендә кулланыла торган шәхси торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш) җир кишәрлекләренә карата;

1.3. 0,1 % – шәхси ярдәмче хуҗалык, бакчачылык яки яшелчәчелек алып бару өчен сатып алынган (бирелгән) эшмәкәрлек эшчәнлегендә кулланылмый торган җир кишәрлекләренә, шулай ук "Гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып баруы һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль законда каралган гомуми билгеләнештәге җир кишәрлекләренә карата;

1.4. 0,3 % – Россия Федерациясе законнары нигезендә әйләнештә чикләнгән, оборона, иминлек һәм таможня ихтыяҗларын тәэмин итү өчен бирелгән җир кишәрлекләренә карата;

1.5. Башка җир кишәрлекләренә карата – 1,5 %.

2. Түбәндәге салым ташламаларын бирергә:

2.1. салым түләүчеләрнең түбәндәге категорияләрен җир салымы түләүдән азат итәргә:

а) оешмалар һәм учреждениеләр –гражданнарны җирләгән җир кишәрлекләренә карата;

б) муниципаль казна учреждениеләре – Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлеге муниципаль берәмлеге территориясе чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләренә карата;

в) Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм инвалидлар;

г) балачактан инвалидлар, инвалид балалар;

д) Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлеге территориясендә яшәүче, Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнары (алга таба – мобилизация буенча чакырылган гражданнар) һәм аларның гаиләләре әгъзалары (ире/хатыны, балигъ булмаган балалары һәм белем бирү оешмаларында көндезге уку формасы буенча укучы 23 яшькә кадәрге балалары»);

е) мобилизация буенча чакырылган гражданнарның алар белән бергә яшәүче (яшәү урыны буенча билгеләнгән тәртиптә теркәлгән) ата-аналары;

ж) махсус хәрби операциядә катнашучы контракт хезмәте хәрбиләре һәм аларның гаилә әгъзалары (тормыш иптәше, балигъ булмаган балалары һәм белем бирү оешмаларында көндезге уку формасы буенча укучы 23 яшькә кадәрге балалары);

з) махсус хәрби операциядә катнашучы, алар белән бергә яшәүче (тормыш урыны буенча билгеләнгән тәртиптә теркәлгән) контракт хезмәте хәрбиләренең әти-әниләре.

Физик затларга ташламалар салым түләүченең сайлавы буенча эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен кулланылмый торган бер җир кишәрлегенә карата бирелүен билгеләргә.

Физик затның салым ташламасына хокукын раслый торган документлар салым түләүче тарафыннан салым органына үз сайлавы буенча тапшырыла.

Әлеге пунктның «д» - «з» пунктчалары нигезендә салым ташламасына хокуклы гражданнар исемлеге Мәмәшир авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан салым органына тапшырыла.

2.2. түбәндәге салым ставкалары күләмен билгеләргә:

а) 0,5 % – белем бирү, фән, сәламәтлек саклау, мәдәният, социаль тәэмин итү, физик культура һәм спорт объектларын урнаштыру өчен билгеләнгән җир кишәрлекләренә карата;

б) 0,9 % – җитештерү һәм административ биналарны, корылмаларны, сәнәгать корылмаларын, коммуналь хуҗалыкны урнаштыру өчен билгеләнгән җир кишәрлекләренә карата;

в) 0,05% – коммерция нигезендә файдаланыла торган 1-3 категорияле гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү һәм эксплуатацияләү өчен бирелә торган җир кишәрлекләренә карата;

г) 0,01 % – «Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) тарафыннан вәкаләтләнгән махсуслаштырылган оешмалар милкендәге җир кишәрлекләренә карата.

3. Салым түләүче оешмалар өчен хисап чорлары булып календарь елның беренче кварталы, икенче кварталы һәм өченче кварталы танылуын билгеләргә.

4. Салым түләүче оешмалар өчен салым түләү җир кишәрлегенең кадастр бәясенең процент өлеше буенча тиешле салым ставкасының 1/4 өлеше күләмендә аванс түләүләре белән башкарыла.

5. Әлеге карар 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә, әмма рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң бер ай узгач кына, әлеге карар белән аларның үз көченә керүенең башка сроклары билгеләнгән нигезләмәләрдән тыш.

6. Әлеге карарның 2.1 пунктындагы «д»,«е» пунктчалары нигезләмәләренең гамәлдә булуы 2022 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

7. Әлеге карарның 2.1 пунктындагы «ж»,«з» пунктчалары нигезләмәләренең гамәлдә булуы 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

8. Әлеге карар законлы көченә кергән көннән алып, Мәмәшир авыл җирлеге Советының 2021 елның 29 ноябрендәге 32 номерлы «Җир салымы турында» карары, «Мәмәшир авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2021 елның 29 ноябрендәге 32 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 25 ноябрендәге 32 номерлы карары, «Мәмәшир авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2021 елның 29 ноябрендәге 32 номерлы карарына үзгәреш кертү хакында» 2023 елның 19 июнендәге 17 номерлы карары үз көчен югалта.

9. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә htth://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында», Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә htth://kukmor.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлеге территориясендәге мәгълүмат стендларында бастырырга.

Мәмәшир авыл җирлеге башлыгы И.Г.Әхмәтҗанов

ОГРН 1021607753012
ИНН 1623001702